**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Совет Балтачевского сельского поселения» Азнакаевского муниципального района**

ул. Молодежная, д 1а , с. Балтачево
Азнакаевского муниципального района
423302, Тел. (8-292) 4-47-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Балтач авылы жирлеге Советы**

Азнакай муниципаль районы, Балтач авылы,
Яшьлэр урамы, 1а
423302, Тел. (8-292) 4-47-23

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» ноябрь 2019 ел № 16

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач торак пунктында, Балтач авылында теркәлгән һәм Яшьләр урамы буенча 1-62, А. Алиш урамы буенча 1-27 нче йортлар буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын 2019 елның 22 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач торак пунктында, Балтач авылында теркәлгән һәм Үзәк урамы буенча 1-32, 8 Март урамы буенча 1-37 нче йортлар буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын 2019 елның 28 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3.Билгеләү:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач авыл җирлегендә үзара салым кертү буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитеты.;

- гражданнар Җыенының беренче этабын уздыру вакыты-2019 елның 22 ноябрендә 15.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар Җыенының беренче этабын уздыру вакыты-2019 елның 28 ноябрендә 15.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр;

4.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 16 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар җыены

карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга Балтач авылы, Молодежная урамы, 1А йорт адресы буенча бирергә.;
"Татар теле" фәнен өйрәнүгә карата уңай омтылышта булу, татар теле белән даими кызыксыну һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татр телен уңышлы үзләштерү.;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
- Балтач торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.
5.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертергә килешәсезме?, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:
- Балтач авылы, Яшьләр урамы, Үзәк урамы, А. Алиш урамы ,8март урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу,ташу, вак таш җәю, эшләр өчен түләү); ;
- Балтач авылында урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;;
Балтач авылында күперне ремонтлау ;
Балтач авыл мәдәният йорты өчен генератор сатып алу;
- Балтачта «Җиңү көне», «Сабантуй» ,«өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;;
Балтачта юлларны кардан чистарту;
- Балтач авылы территориясендә чүп үләнен чабу;
Балтач авылы зираты территориясендә чүп үләннәрен чабу

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Балтач авылы, Яшьләр урамы., 1А йорт,Узәк урам 37йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: Л. Л. Хәбипов